# КАРАР

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге составына керүче Чепья авылы, Янгурчы авылы торак пунктытларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 30 октябере № 9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 30 октяберендэ узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Чепья авыл, Янгурчы авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган - 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендәге контракт буенча хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары тыш; 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү күздә тотыла. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

торак пункт территориясен төзекләндерү.»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 1148 кеше гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән, тавыш бирүдә 581 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

"Әйе" позициясе өчен җыенда катнашкан 581 кеше тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Чепья авылында , Янгурчы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

"Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Чепья авыл, Янгурчы авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган - 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендәге контракт буенча хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары тыш; 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү күздә тотыла. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

торак пункт территориясен төзекләндерү.»

2. Җыенның нәтиҗәләрен Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru бүлектә авыл җирлекләре кабул ителгән көннән 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче
Чепья авыл җирлеге башлыгы А. Г. Нотфуллин